ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32[1] статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 32 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарның җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәве турында әлеге пунктның 1 пунктчасында каралган таләп, ата-ананың берсе генә булса да яисә ялгыз ата йә ана хәрби хезмәткәр булса, кулланылмый.»;

2) 32[1] статьяның 10 пунктында:

а) түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәр статусын таныклаучы документ (ата-ананың берсе яисә ялгыз ата йә ана хәрби хезмәткәр булса).»;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның 9 пунктчасында күрсәтелгән документ гариза бирүче «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәр статусына ия булган очракта тапшырылмый.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 16 ноябрь
№ 114-ТРЗ